СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.06.2020 № 48/8

На № ________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль милектән һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль милектән һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 10.06. 41/8 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль милектән һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү тәртибе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә гамәлдәге законнар нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль милектән һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү тәртибен билгели.

1.2. Түбәндәге очракларда милек һәм җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча бурыч, шулай ук аренда түләүләрен вакытында түләмәгән өчен исәпләнгән пенялар (алга таба - бурыч) түләтелүгә өметсез дип таныла һәм исәптән төшерелергә тиеш:

1) физик затның үлеме яки Россия Федерациясе Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аны вафат булган дип игълан итү;

2) шәхси эшмәкәрне - бурычлыны «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бурычлының мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле түләнмәгән бурыч өлешендә банкрот дип тану;

2.1) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси эшмәкәр булмаган гражданны күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бурыч өлешендә банкрот дип тану;

3) оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, түләнмәгән бурыч өлешендә оешманы - бурычлыны ликвидацияләү;

4) штрафка тарту яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә җәзага тартылганнарга карата амнистия турында яки кичерү турында актлар куллану, аның нигезендә бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеге югала.

5) әгәр бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узса, түбәндәге очракларда суд приставы-башкаручы тарафыннан башкару производствосы

тәмамлану һәм «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлеше 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтару турында карар чыгару:

- бурыч күләме бурычлыга карата банкротлык турында эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләр күләменнән артмый;

- суд тарафыннан бурычлыны банкрот дип тану турында гариза кире кайтарылган яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, банкротлык турындагы эш буенча производство туктатылган;

6) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, түләнмәгән бурыч өлешендә суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлеше 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтару сәбәпле башкару производствосы тәмамлану турында карар булу. Теркәүче органның «Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затларны бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карарын гамәлдә түгел дип тану очрагында, әлеге пункт нигезендә түләтүгә өметсез дип табылган бурыч яңадан торгызылырга тиеш;

7) законлы көченә кергән суд карары булу, аның нигезендә түләттерүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле бурычларны түләттерү, шул исәптән бурычларны түләтү турында судка гариза бирүнең югалган срогын торгызудан баш тарту турында суд карары чыгару мөмкинлеге югала;

8) законлы көченә кергән, башка нигезләр буенча бирелгән таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тартылган суд карарының булуы.

## II. Бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү турында карар кабул итү тәртибе

2.1. Бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү турында карар Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган комиссия (алга таба - Комиссия) тарафыннан кабул ителә.

2.2. Комиссия тапшырылган мәгълүматларны карый, аларның дөреслеген тикшерә һәм бурычларны исәптән төшерү яки аларны тапшырганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, исәптән төшерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.3. Комиссия карарлары һәр арендачы - бурычлы буенча шәхси рәвештә комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

2.4. Комиссия карары өч нөсхәдә беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе һәм документларны карауда катнашкан барлык әгъзалар имзалый.

2.5. Бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү комиссия карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән башкарыла.

### III. Бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү өчен кирәкле документлар исемлеге

3. Бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм исәптән төшерү турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

3.1. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең күчермәләре;

3.2. Башкарма хакимият органы тарафыннан төзелгән, җир кишәрлегенең буш булуын яки башка оешма (юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат) тарафыннан кулланылуын раслый торган җир кишәрлегеннән фактта файдалануны тикшерү акты;

3.3. Исәптән төшерелергә тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.4. Юридик затның теркәлү урыны буенча салым органы тарафыннан бирелгән, юридик затны дәүләт теркәвенә алу, бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану аркасында яки башка нигезләр буенча ликвидацияләү турында белешмәләрне үз эченә алган юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр;

3.5. Шәхси эшмәкәрнең теркәлү урыны буенча салым органы тарафыннан бирелгән, шәхси эшмәкәрләрнең физик зат буларак эшчәнлекне туктатуны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне үз эченә алгана бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр;

3.6. Юридик затны яисә шәхси эшмәкәрне бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында законлы көченә кергән арбитраж суды карарының тиешле арбитраж судының герб мөһере белән расланган күчермәләре;

3.7. Конкурс производствосы тәмамлану турында арбитраж суды билгеләмәсенең күчермәләре (бурычлыны конкурс массасы хисабына түләнмәгән бурычлары булганда бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип таныган очракта);

3.8. Физик затның үлеме турында таныклыкның күчермәләре яки физик затның вафат булуын игълан итү турында суд карарының күчермәләре;

3.9. Мирас эшен ачу урыны буенча нотариус тарафыннан бирелгән мирас хокукы турында таныклыкларның күчермәләре;

3.10. Мирас кабул итүче физик затларның шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре;

3.11. Кабул ителгән мирас милке бәясен раслый торган документ;

3.12. Үлгән яки суд тарафыннан вафат булуы игълан ителгән затның варисы тарафыннан бурычны мирас мөлкәте бәясеннән түләүне раслаучы документ яисәваристан күрсәтелгән бурычны түләттерү мөмкинлеге булмау турында документ;

3.13. Үлгән яки суд тарафыннан вафат булуы игълан ителгән затның мирас милкенең дәүләткә күчүен раслаучы документ (закон буенча да, васыять буенча да варисларның булмавын раслаучы тиешле нотариус белешмәсе, варисларның берсе дә мирас итеп алырга хокуклы түгел, яки барлык варислар да варис булудан читләштерелгән, яисә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яисә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән);

3.14. Арендачының - бурычлының теркәлү урыны һәм урнашу урыны турында мәгълүматларның булмавы хакында салым органы мәгълүматы (юридик затлар өчен арендачының - бурычлының урнашу урыны турында, физик затлар өчен арендачының - бурычлының яшәү һәм тору урыны турында);

3.15. Башкарма битнең күчермәләре;

3.16. Башкарма производство тәмамлануы турында, башкарма документ түләтүчегә кайтарыла торган хәлләр барлыгы турында суд приставы - башкаручы актлары күчермәләре («Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә).

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Бурычларны исәптән төшерү белән бәйле үзгәрешләр җирле үзидарә органының карар кабул ителгән айдан соң килүче айның беренче числосына финанс хисаплылыгына кертелә.